Thus, Razil Valeev, with his multifaceted creative work, breathed new life into Tatar poetry. In the poem "Keshe" ("Man") (1968), written in the early period of his literary career, he wrote the following lines, definting his life and creative credo:

| | | |
|---|---|---|
| Күпме тырышсаң да булмый мине Хәят диңгезендә батырып! [5, 35 б.] | Kupme tyryshsan da bulmyi mine Kheyet dingezende batyryp! | No matter how hard you try, You can't drown me in fate. [5, p. 35] |

The poetry of R. Valeev, who managed to convey through his experiences the fate of the people, who worried about the present and the future of his people, burning with the ideal of reviving the spirit of humanity, testifies to his loyalty to his vocation. Reviving national traditions in the mid-20th century, enriching them with new strategies of verbal and visual creative work, he left Tatar poetry a unique, rich and multifaceted oeuvre.

**References**

1. Vəliev, R. (1971). *Zəңgər kabyrchyklar: shigyr'lər* [Blue Shells: Poems]. 93 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

2. Vəliev, R. (1977). *Yashen tamyry: shigyr'lər həm җyrlar* [The Root of Lightning: Poems and Songs]. 127 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

3. Vəliev, R. (1987). *Yadkar': shigyr'lər, җyrlar* [Heritage: Poems and Songs]. Kazan: Tatar. kit. nəshr., 1987. 144 b. (In Tatar)

4. Vəliev, R. (1992). *Ber almany bishkə byləek: җyrlar* [We Would Cut an Apple into Five Pieces: Songs]. 144 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

5. Vəliev, R. (1994). *Kyshky uchak* [The Winter Fire]. 382 p. Kazan, Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)

6. Vəliev, R. (1996). *Syzlərdən disbe: shigyr'lər, җyrlar* [The Rosary from Words: Poems, Songs]. 224 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

7. Vəliev, R. (1999). *Sailanma əsərlər: shigyr'lər, җyrlar* [Selected Works: Poems, Songs]. 4 kitapta. Kit.1: shigyr'lər, җyrlar. 568 p. Kazan, Milli kitap. (In Tatar)

8. Vəliev, R. (2006). *Əsərlər: shigyr'lər, җyrlar: 4 tomda* [Works: Poems, Songs: In 4 Volumes]. T.1, Shigyr'lər, җyrlar. 527 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

9. Vəliev, R. (2011). *Køz balkyshy: shigyr'lər* [An Autumn Sparkle: Poems]. 279 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

10. Vəliev, R. (2015). *Məkhəbbət həm nəfrət: shigyr'lər, povest'lar, istəleklər* [Love and Hate: Poems, Stories and Memoirs]. 543 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

11. Oshanin, L. (1979). *Razil Vəliev* [Razil Valiev]. Kazan utlary. No.10, pp. 80–82. (In Tatar)

12. Galiev, M. (2005). *Yazmyshka rəkhmət* [I Thank You, Fate]. Galiev M. Rukh: fəlsəfi yazmalar, ədəbi portretlar. Pp. 332–355. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

13. Gosmanov, M. (2004). *Altyn busagany atlaganda* [When Crossing the Golden Threshold]. Gosmanov M. Gasyrdan – gasyrga. Pp. 334–339. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

14. Khisamov, N. (2010). *Keshe atly ber kyitga min...* [I'm a Continent Called Man….]. Mədəni җomga. 24 dek., pp. 14–15. (In Tatar)

15. Khisamov, N. (2012). *Iҗatchynyң shig"ri dən'yasy* [The Poetic World of the Creator]. N. Khisamov. Tatar shagyir'ləre: monografik məkalələr, iҗat portretlary həm ehtyudlar. Pp. 239–247. Kazan, Tatar kit. nəshr. (In Tatar)

16. Zahidullina, D. (2019). *Razil Vəliev* [Razil Valiev]. Tatar ədəbiyaty tarikhy: 8 tomda. T 7: 1985–2000 ellar. Pp. 289–309. Kazan, "Foliant" nəshr. (In Tatar)

17. Zəidulla, R. (2011). *Dulkyn bieklege* [The Height of a Wave]. Vəliev R. Køz balkyshy: shigyr'lər. Pp. 2–7. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

18. Miңnullin, T. (2016). *Talantly buynnyң ber vəkile* [A Representative of the Talented Generation]. Mədəni җomga. 16 dek, pp. 8–9. (In Tatar)

19. Gatash, R. (2012). *Dөn'ya gamen җanga uidyryp...* [Thinking about the World]. Mədəni җomga. 6 aprel'. Khəsənova A. Shagyir' disbese, Vatanym Tatarstan. 11 aprel', p. 2. (In Tatar)

20. Yatimova, F. (2008). *Osobennosti yazyka i stilya poehzii Razilya Valieva: avtoreferat diss.... kand.filol.nauk* [Features of Razil Valiev's Poetry Language and Style: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 22 p. (In Russian)

21. *Terminologiya sovremennogo zarubezhnogo literaturovedeniya* (1992) (Strany Zapadnoi Evropy i SSHA) [Terminology of Modern Foreign Literary Criticism (Western European Countries and the USA)]. Otv. red. I. P. Il'in, E. A. Tsurganova. 218 p. Moscow, INION. (In Russian)

22. Borukhov, B. (1992). *Vvedenie v motiviruyushchuyu poehtiku* [Introduction to Motivational Poetics]. Filologicheskaya germenevtika i obshchaya stilistika. Pp. 5 – 28. Tver', izd-vo Tverskogo un-ta. (In Russian)

23. Yusupova, N. (2021). *XX gasyrnyң ikenche yartysy tatar shig"riyate: traditsiyalər həm yaңachalyk* [Tatar Poetry in the Second Half of the 20th Century: Traditions and Innovations]. 296 p. Kazan, "Shkola" redaktsiya nəshriyat үzəge. (In Tatar)

---

# «ДИСБЕ ҖЫЯМ СҮЗЛӘРДӘН... »: РАЗИЛ ВӘЛИЕВ ШИГЪРИЯТЕНЕҢ ПОЭТИК ХАСИЯТЛӘРЕ

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru.

Мәкалә Разил Вәлиевның тормыш һәм иҗат юлын яктырта, шигъри үрнәкләргә анализ аша әдәбият мәйданында ул үстереп алып киткән традицияләрне һәм алып килгән яңачалыкларны төгәлләштерә барып, шагыйрьнең XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар поэзиясендәге урынын билгели. Әдип сүз сәнгатенең өч төрендә дә нәтиҗәле эшләсә дә, нәкъ менә шигърият мәйданында үз йөзе булган талантлы шагыйрь буларак танылa. Әлеге мәкалә шуны раслап, мотивлаштырылган поэтика алымнары нигезендә шагыйрьнең татар шигърияте өчен «программ» әсәрләргә әверелгән күп кенә шигырьләренә яңача караш ташлый, иҗатының йөзен билгеләгән төп тенденцияләрне аерып куя. Үзәк мотивлар, лирик герой концепциясенә, шигырь поэтикасына Р. Вәлиев алып килгән яңалыклар XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы әдәби барышы контекстында төгәлләштерелә. Мәкаләнең яңалыгы һәм актуальлеге шуның белән билгеләнә. Мәкалә чикләрендәге эзләнүләрнең төп максаты – Разил Вәлиевның тормыш, аеруча иҗат биографиясен өйрәнү, ул алып килгән яңалыкларны, аның поэзия үсешенә керткән өлешен төгәлләштерү. Эзләнүләр нәтиҗәсендә Р. Вәлиев иҗатында гыйсъянчылык традицияләренең яңарышы, шушы фонда лирик герой концепциясенең, мотивларның үзгәреше, эзоп теле алымының символлар бирелеше һәм янәшәлек аша үткенәйтелүе, күңел лирикасы үрнәкләрендә фольклор стиленең калкулануы төгәлләштерелә. Шагыйрьнең Такташ рухындагы авангард традицияләрне үз чорына яраклаштырып яңартуы, хөр фикерле лирик геройны күтәрүе, поэтик яссылыкта шактый бай һәм үзенчәлекле экспериментлар ясавы, эзләнүләр алып баруы күпсанлы әсәрләргә анализ аша дәлилләнә.

**Төп төшенчәләр:** Разил Вәлиев, лирик герой, поэзия, образ, жанр, мотив, әдәби алым, эзоп теле, фольклор стиле, гыйсъянчылык

## Кереш

Үзенчәлекле шигъри теле, кеше, ил, халык-милләт язмышы, яшәү мәгънәсе хакында уйлануларга бай, хис-тойгы тирәнлегенә, вакыты белән гыйсъяный кайнарлыкка, композицион һәм ритмик төзеклеккә ия шигърияте, төрле жанрларны колачлаган иҗаты белән Разил Вәлиев XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертә. Шагыйрь гасырлар дәвамында чарланган классик традицияләрне дәвам итеп, аларны үстереп-камилләштереп кенә калмый, татар шигъриятен сүз-сурәт үткенлеге, фикер-фәлсәфә ягыннан баета. Иллегә якын китап, дүрт пьеса, 200 ләп җырлар авторы буларак, ул әдәбиятның өч төрендә – поэзия, проза, драматургиядә актив иҗат итә,

шуның белән янәшәдә танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булып танылa.

Разил Исмәгыйль улы Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварында Татарстанның Түбән Кама районы (элекке Ширәмәт районы) Ташлык авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, укуын күрше Шәңгәлче сигезьеллык мәктәбендә дәвам итә, аны тәмамлаганнан соң, белемгә омтылган егет Түбән Кама шәһәренең беренче номерлы урта мәктәбенә юл ала.

Мәктәптә укыганда ук ул шигырьләр һәм хикәяләр язу белән мавыга башлый, берничә шигыре район газетасы битләрендә дә басылып чыга. Иҗатка омтылыш 1965 елда булачак әдипне Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә алып килә. Такташ шигырьләреннән йоккан гыйсъяный рух аның күңелен даими алгысыта, каядыр әйдәкли. 1968 елда берничә сабакташы белән Р.Вәлиев татар язучылары корылтае вакытында, «Идел» журналын чыгаруны, яшьләргә мәйдан бирүне таләп итеп, залга листовкалар ташлый. Үз чоры өчен гаять батыр һәм кыю адым була бу. Шушы бунтарь холык бераздан шактый гына каләм чарлый башлаган егетне, әдәби белемне тирәнәйтү максатыннан, СССР Язучылар берлегенең М. Горький исемендәге Әдәбият институтына алып китә.

Әлеге институтны тәмамлаганнан соң, Казанга кайтып, Р. Вәлиев журналистика өлкәсендә эшләвен дәвам итә. «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы сәркатип баскычларын үтә. Әлеге чорда ул максатчан төстә балалар өчен әсәрләр язу эшенә чума, ике шигъри китап һәм проза әсәрләре, сәнгать әһелләренә багышланган очерклары дөнья күрә. Шушы елларда Р. Вәлиев тәрҗемә эше белән дә мавыгып китә, дөнья халыклары әкиятләрен, А. де Сент-Экзюпериның «Нәни принц», К. Дойлның «Баскервильләр эте», Р. Киплингның «Маугли» әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

1981 елда Р.Вәлиев Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы җитәкчесе итеп билгеләнә, ә 1984 елда Татарстан язучылары съездында Язучылар берлеге идарәсенең рәис урынбасары итеп сайлана. 1986 елда инде Татарстанның Милли китапханәсе директоры вазифасына алына һәм бу вазифада 2000 елга кадәр уңышлы эшли, китапханәнең эш юнәлешләрен киңәйтә. 1989 елда «Җыен» фондын оештыруда актив катнаша һәм аның юнәлешен, мәсләген билгеләүчеләрнең берсе була. Нәкъ менә әлеге фондның эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар дөньясында билгеле эз калдырган күп кенә шәхесләрнең эш-гамәлләре һәм хезмәтләре киң катлам халыкка кайтарыла, татар халкына кылган игелекле эшләре дөньяга ачыла.

Шушы еллардан Р.Вәлиевның актив иҗтимагый эшчәнлеге башланып китә. 1990 елдан ул Татарстанның халык депутаты итеп сайлана, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, президиум әгъзасы, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Химаячеләр шурасы рәисе, Бөтендөнья язучылар ассоциациясенең Татар ПЕН-үзәге вице-президенты (1995) һәм президенты (2008) була. Күп кенә иҗтимагый һәм мәдәни фондлар, комиссияләр, оешмалар әгъзасы булып тора, Татарстан Республикасының сәяси-иҗтимагый һәм икътисади-мәдәни тормышына кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүдә турыдан-туры катнашып, милләт өчен файдалы шактый эшләр башкара.

Р. Вәлиевның әлеге эш-гамәлләре дәүләт тарафыннан да, халык тарафыннан да үз бәясен ала, ул – Татарстанның (1990) һәм Россиянең (1997) атказанган мәдәният хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты (2005), «Казанның 1000 еллыгы» (2006), «Фидакяр хезмәт өчен» (2016) медальләре, Татарстан Дәүләт Советының «Парламентаризмны үстерүгә керткән өлеше өчен» (2015) почёт билгесе, «Планетада цивилизацияне, яшәешне һәм мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә керткән хезмәтләре өчен» халыкара көмеш медале, Россия Язучылар берлегенең «Василий Шукшин» медале, «Казанның үсешенә керткән хезмәте өчен» медале иясе. «Иске сәгать дөрес йөри» (2004) исемле роман һәм повестьларны эченә алган җыентыгы һәм «Ядкарь» (2005) җырлар китабы өчен 2007 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. 2011 елда Р.Вәлиевка «Татарстан Республикасының халык шагыйре» исеме бирелә.

Шагыйрьнең татар телендә дистәдән артык шигырьләр җыентыклары басылып [1; 2; 3; 4; 5; 6; 7; 8; 9; 10], иҗаты һәм шигърият өлкәсендәге эшчәнлеге турында Л. Ошанин [11], М. Галиев [12], М. Госманов [13], Н. Хисамов [14; 15], Д. Заһидуллина [16], Р. Зәйдулла [17], Т. Миңнуллин [18], Р. Гаташ [19], Ф. Ятимова [20] кебек галим, тәнкыйтьче-публицистларның, әдипләрнең аерым мәкаләләре, истәлек-язмалары дөнья күрә. Шулай да Разил Вәлиев

шигъриятен заман күзлегеннән, яңа методологик нигездә бәяләү, аның татар шигърияте үсешенә керткән өлешен, поэзия мәйданындагы урынын билгеләү актуаль булып кала.

### Хезмәтнең методологик нигезе

Хезмәтнең методологик нигезе булып, герменевтик эзләнүләр [21], методик нигезе булып Б.Л. Борухов тәкъдим иткән «мотивлаштырылган поэтика» тора. Галим аңлатуны фәнни эшчәнлекнең ахыргы максаты буларак билгели һәм әдәби текстны анализлау өчен төп метод итеп канун (закон) нигезендә аңлатуны аерып чыгара, аны текстны мотивацияләү дип атый [22]. Б.Л. Борухов мотивацияләүнең мәдәни, конвенциаль, менталь төрләрен аерып чыгара [22, 13 б.]. Разил Вәлиев шигъриятен өйрәнү юлында аның конвенциаль тибы үзәккә куелды. Әлеге төр тикшеренүләр әдәби текстлар һәр чорда үз кануннарына буйсынып яки аларны кире кагып, мәйданга чыга дип белдерә. Конвенциаль мотивацияләү Разил Вәлиев шигъриятенең төп поэтик хасиятләрен аерып чыгарырга, иҗатындагы төп үсеш юнәлешләрен, теге яки бу әдәби традицияләрнең яңарышын яки трансформациясен ачыкларга ярдәм итә.

### Фикер алышу

Р. Вәлиев олы шигърият мәйданына 1960 елларның икенче яртысында килә, әдәби тәҗрибәләре Мәскәүдә Әдәбият институтында уку елларында ук күренә башлый. Биредә уку аның әдәби талантын үстерә, төрле яклап иҗат мөмкинлекләрен ача, шушы вакытта Р. Вәлиев танылган җырлар авторы Лев Ошанин тәэсирендә җыр текстлары яза башлый.

Мәскәүдә узган еллар шагыйрь өчен тагын бер ягы белән кадерле була – биредә аның «Зәңгәр кабырчыклар» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Шигырьләр язу белән беррәттән, 1968 елда Р. Вәлиев «Эт кояшы» исемле беренче повестен яза һәм танышу өчен кулъязмасын Аяз Гыйләҗевкә җибәрә, таләпчән язучы повестька югары бәя бирсә дә, совет әдәбияты кысаларында иҗат ителмәү сәбәпле, әлеге әсәр тулысынча 22 елдан соң гына татар укучысы кулына барып ирешә ала. Әмма Р. Вәлиев күңелен төшерми, Александр Матросовның батырлыгын кабатлаган Рифкать Миргазизовка багышланган «Яшисе килә» (1978-79) исемле повестен язып тәмамлый. Әдипнең 1982 елда ТАССРның М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булган әлеге әсәре бик тиз танылу ала, күп кенә журналларда, альманахларда дөнья күрә, рус теленә дә тәрҗемә ителеп, Мәскәү нәшриятларында басыла.

М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укыган елларында Р. Вәлиев иҗат каләмен драматургия өлкәсендә дә сынап карый: аның «Яшел күзле такси» исемле кечкенә күләмле әсәре институт күләмендә үткәрелгән конкурста беренче урынны ала. Соңрак Р. Вәлиевның «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!» (1989), «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990), «Куркыныч уен» (1989) һ.б. пьесалары язылып, күбесе К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры, шулай ук республиканың башка театрлары сәхнәләренә менә.

Үзенең каләмен әдәбиятның өч төрендә дә актив сынап караса да, әдәбият мәйданында Р. Вәлиев иң беренче чиратта ШАГЫЙРЬ буларак танылу ала. Әдипнең беренче чор иҗаты авангард поэзия кысаларында иҗат ителеп, көчле гыйсъяный рух, максималист лирик геройның алга чыгуы белән характерлана. Әлеге шигырьләре белән Р. Вәлиев, иң беренче чиратта, татар шигъриятендә лирик герой концепциясен үзгәртә, кискен, Такташ рухындагы бунтарь лирик геройны шигърият киңлекләренә кайтара һәм халык арасында киң танылу ала. Аның лирик герое төп кыйммәт итеп гаделлекне, рухи матурлыкны күтәрә һәм кешелекнең эш-гамәлләрен дә шушы бизмәннәргә салып үлчи, дөньяны үзгәртү теләге белән яна. Мондый шигырьләрдә кешене зурлау фәлсәфәсе алга чыга. Шагыйрьнең зур иҗатка аяк баскан чорында ук Такташтан «...Әйе, минем көчле рухымнан / җир вә күкләр калтырар» кебек юлларны эпиграф итеп алып язылган «...Елыйелый, сугыша-сугыша җирдә....» шигыре татар шигъриятенең «визит карточкасы»на әйләнә:

Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса, үзем үзгәрәм... [5, 14 б.]

Шигырьнең «Үлем белән якалашканда да / Акны кара диеп сөйләмәм» диюче лирик герое дөньяны үзгәртә һәм хакыйкатьне урнаштыра алачагына олы ышаныч белдергән шәхес, хаксызлыкка каршы көрәш аша тормышны үзгәртергә алынган кеше булып күзаллана. Үз чоры өчен мондый кискен лирик герой бөтенләй үзгә һәм яңа була. «Һәр нәрсәгә минем үз атамам / Айны кояш диям, теләсәм» дип, лирик герой дөньяны үзгәртү юлында бернинди киртәләр алдында да туктап

калмаячагы турында сөйли һәм хаксызлыкка каршы көрәштә каләм көченә таянуын белдерә:

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса, үзем үзгәрәм [5, 14 б.].

Акылы җавап табалмаган, яшәештәге хаксызлыкларны, аңлашылмаучылыкларны, икейөзлелекне күреп, уңы-сулы буталган гыйсъянчы лирик герой ярсый, шаша, яшәеш кыйммәтләрен кире кага һәм «Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген / Йә булмаса үзем үзгәрәм» гыйбарәсен кабатлау аша үз хакыйкатен урнаштыра:

Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,
Матурлыкны күреп тезләнәм.
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса, үзем үзгәрәм [5, 14 б.].

«Кеше» (1968) шигыре дә шушы яссылыкта кабул ителә. Биредә лирик герой үзенчәлекле яңгыраш алган метафора-эпитетлар, символик эчтәлекле образ-детальләр аша Кешене галәм югарылыгына күтәрә:

Бу дөньяның мин бер кисәкчеге,
Мин кечкенә генә материк.
Таулар да бар миндә, упкыннар да,
Батырлык бар миндә, матурлык.
Бу дөньяның мин бер материгы,
Урман миндә чәч дип атала...
Минем кояш – бәхет, аем – шатлык,
Яңгыр булып миннән тир тама.
Кайгыларым җир тетрәве төсле,
Сагышларым – гүя ак томан,
Чишмәләрем – чиста күз яшьләрем,
Ә сүзләрем буран, җил сыман [5, 31 б.].

Алга таба шигырь Кешене югары күтәрүнең сәбәпләрен чарлый башлый. Шагыйрь аның Җир шарыннан өстенлеген Хәтер, Акыл һәм Рух бөеклеге белән бәйләп куя. Шушы өч алтын багана Кеше яшәешендәге төп терәк, батырлыкларның нигезе итеп раслана:

Кеше атлы нәни материк мин...
Матурлык бар миндә, батырлык.
Күпме тырышсаң да булмый мине
Хәят диңгезендә батырып! [5, 32 б.]

«Мизгел» (1971) шигырендә дә кешенең зурлыгы, бөеклеге аның фикри һәм рухи көче, йөрәк матурлыгы, яшәештәге күренешләрне тоя һәм бәяли алырлык сизгерлеге белән бәйләп куела. Әлеге югарылыкка Р. Вәлиев Шагыйрьне күтәрә:

Бизмәнләдем күз яшьләрен, таң чыкларын –
барын, барын, барын.
Тик төннәрен януларын,
Бер мизгелгә
уч төбенә куеп тордым.
Әйе, әйе,
мин бер мизгел
шагыйрь булып алдым [5, 46 б.].

Шагыйрьнең 1960 еллар ахырында дөнья күргән «Дисбе» шигырендә дә яшәеш кануннарын кире каккан һәм Иҗатны югары күтәргән лирик герой алга чыга. «Минем, әби, хәзер үз Аллам» дип белдергән лирик герой, әбисенең дисбесен кулына алып, әтисенең, үзенең динсез һәм денсез үткән елларын барлый, шул рәвешле үз чорының яшәеш кыйммәтләрен кире кага. Гыйсъянчылык поэзиясе традицияләрен дәвам итеп, Шигърияtне илаһи югарылыкка күтәрә һәм аның бөеклеген Әдәби сүзнең кешелекне туры юлга күндерүенә мөнәсәбәтле аңлата:

Дисбең исән... Күрсәң иде, әби,
Дөнья хәзер ничек үзгәргән...
Ә мин һаман тугрылыклы сиңа:
Дисбе җыям, әби, сүзләрдән [5, 65 б.].

Шушы ук елларда француз модернисты Шарль Бодлерга багышлап язылган «Шагыйрь» шигырендә дә рухи хөрлек иҗат кешесе белән бәйләп куела. Француз шагыйренең тормыш юлын тергезеп, Р. Вәлиев аның тормыш фаҗигасен дүрт гыйбарә аша ачып бирә: аны аңламадылар, сөйләгәнен тыңламадылар, язган җырын җырламадылар, ашыкмауларын сораса да, еллар соңламадылар. Шагыйрь теләкләренең үзе үлгәннән соң гына тормышка ашуы исә фаҗигалелекне тагын да көчәйтә һәм шагыйрь фаҗигасен кешелек фаҗигасенә әйләндерә:

Менә бүген
Барысы үтте, барысы бетте.
Кешеләр аны әрнеп тыңладылар...
Аңладылар... Соңладылар...
Каберенә башлар орып,
Җырын тыңладылар [5, 67 б.].

Үлем һәм үкенеч мотивларына бәйле төстә шигырь структурасында экзистенциаль халәт тудырыла: кеше гомере чикләнгән, ул вакытлы, кешенең кадере үзе исән чакта беленергә тиеш! Бу халәтне автор яшәешнең иң олы гаделсезлеге буларак бәяли.

Авангард юнәлештәге башка шигырьләрдә дә Кеше Җир шарын үзе теләгәнчә яшәтә алырлык илаһи югарылыкта сурәтләнә һәм автор фикере гаҗәп үзенчәлекле образлар һәм стиль аркылы җиткерелә. Нәкъ менә образлар белән оста эш итү сәләте шагыйрьгә үз чоры өчен гаять кыю яңгырашлы фикерләр җиткерү мөмкинлеген бирә дә. Мәсәлән, «Мизгел» (1971) шигырендә лирик герой болай дип белдерә:

Җир шарына утырып тәмәке төрдем,
Җир шарына басып сүндердем.

Җир шарында арлы-бирле атлап йөрдем [5, 71 б.].

Мондый лирик геройның совет әдәбияты чикләрендә мәйданга чыгуын исәпкә алганда, бу шигъри үрнәкләр әдипнең шактый кыю фикерле, принципиаль карашлы булуын тагын бер кат исбатлый.

Шагыйрьнең 1970 еллардан соң язылган шигырьләрендә ярсу кими төшә һәм шигъриятендә ике тармак аерылып чыга: аерым шигырьләре салмак лирика традицияләрен дәвам итеп, фольклор стилен үстереп алып китә, икенче төркем шигырьләре, аеруча гражданлык лирикасы кысаларында язылганнары, эзоп-киная телен үз итеп, икенчел эчтәлек алымы ярдәмендә җәмгыятькә бәя бирү юлын үз итә.

Шагыйрьнең бер төркем әсәрләрендә халык җырына, аһәңенә, образлылыгына якынаю күзәтелә [16, 292 б.], мондый үрнәкләрдә «салмак лирика» агымы традицияләре алга чыга. Билгеле булганча, «салмак лириклар» иҗатына лиризм, гади һәм традицион шигъри сөйләмгә өстенлек бирү хас; традицион шигърият вәкилләрен сүз сәнгатенең үткән, бигрәк тә халык җыры, Тукай традицияләренә таяну, әхлакый яңаруга омтылыш якынлаштыра һәм бу сыйфатлар татар шигъриятенең милли нигезләргә «кайтуын» тәэмин итә. Әлеге яңарыш та кеше концепциясендәге үзгәрешләрдән башлана. Хөр фикерле, максималист, романтик-көрәшче лирик геройга алмашка милли яшәеш кыйммәтләрен эзләүче, бай күңел дөньясына ия лирик герой килә. Ул әсәрләрдәге дөнья сурәтен үзгәртә, шушы яссылыкта ике хасият ачык билгеләнә: бердән, иҗтимагый, шәхси каршылыклар сәяси яссылыкка кагылмый, икенчедән, консерватизм пафосы – үткәннән килгән тәртип-гадәтләрне саклап, буыннарга җиткерү теләге көчәя. Шушы дулкында авыл, мәхәббәт, хезмәт темалары активлаша, алар фәлсәфи уйланулар белән баетыла. Катлаулы авангард образлар урынына милли шигърияттә элеккедән яшәгән саф сулы чишмә, урман, болын, туган якның иксез-чиксез басу-кырлары, ак каеннар, имәннәр, шомырт-баланнар, тал-тирәкләр, гармун, сандугачлар һәм былбыл, аккош һ.б. романтик образ-детальләр активлаша. Шагыйрьләр халыкчан фикерләүгә, классик шигырь өлгесенә, көйле тезмәгә әйләнеп кайта. Бер яктан, салмак поэзияне фольклордагы халык акылы, фәлсәфәсе, фикерләү үзенчәлеге кызыксындырса, икенчедән, авыз иҗатына хас романтик образлылык, халык җырларының үлчәм-вәзене, структурасы җәлеп итә, шулар нигезендә 1920-1930 еллар лирикасында формалашкан «фольклор стиле» яңара. Халык авыз иҗатыннан килгән образларны, мотивларны файдалану, символлар куллану татар шигъриятенең эчтәлек һәм форма ягыннан киңәюенә китерә [23, 97 б.]. Саф татарча «җырлап торган» фольклор стиле Р. Вәлиев иҗатында милли моңлы һәм яңгырашлы лирик әсәрләрнең активлашуын тәэмин итә.

Мондый юнәлештәге әсәрләрдә, кагыйдә буларак, мәхәббәт темасы калкулана, гомумән, Р. Вәлиев иҗатында мәхәббәт темасы аерым урын тота. «...Хатларыңны утка яктым синең...» (1971), «...Сине эзләп, мин тауларга мендем...» (1977), «Саубуллашу» (1977), «...Күзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...» (1971), «Яшьлегем канатында» (1986), «Бәхетем ачкычы» (1987) һ.б. күпләгән шигырьләре шул хакта сөйли. Мондый шигырьләрдә, гадәттәгечә, пейзаж күренешләре, табигать образлары һәм йөрәк образы актив. Мәсәлән, 1980 еллар уртасында язылган «Йөрәк дәшә» шигырендә йөрәк галәмнән дә югары күтәрелеп, кеше рухының бөеклеген тәэмин итүче буларак ачыла, бу бөеклек исә мәхәббәт белән бәйләп аңлатыла. «Йөрәк аңлармы, йөрәк җырлармы, йөрәк түзәрме» гыйбарәләре аркылы лирик герой үз мәхәббәтенең көче турында сөйли. Яисә «Гашыйк булгач» (1970) шигырендә табигать образлары шушы максатка хезмәт итә:

Бер тамчы су – төссез.
Бер бүлмә һава – төссез.
Океан – зәңгәр.
Күк тә зәңгәр.
Кайчандыр бу күзләр төссез иде...
Хәзер – зәңгәр! [5, 20 б.]

Бер генә строфадан торган иреклe шигырьдә автор мәхәббәткә бәйле фәлсәфәсен җиткерә: мәхәббәт – кеше яшәешендәге иң олы көч, ул кешенең күзләрен, күңелен, йөрәген «төскә манган» кебек үк, аның яшәешен, гамәлләрен дә олы мәгънәгә «мана». «Мәхәббәт» (1969-1970) шигырендә дә шушы фәлсәфә үстерелә:

Монда Кояш
океан төбеннән күтәрелә.
Монда сукбай һәм буйдак Ай –
кул сузымы җитә.
Монда давыл
дулкын биеклеге белән үлчәнә...
Монда төн һәм көн бар,
Кыш һәм җәй юк.
Монда
шигырь,
шигырь,

шигырь –

Шагыйрьләр юк [5, 76 б.].

Бер яктан, шигырь структурасында кояш һәм океан, ай, болыт һәм сукмак, көн һәм төн, җәй һәм кыш кебек бинар оппозицияләр аркылы мәхәббәтнең гашыйк кеше өчен үзе бер галәм, үзе бер дөнья булуы ассызыклана. Ахыр чиктә мәхәббәтнең шигырь булуы искәртелеп, шуның аша ике йөрәк иҗат иткән илаһи дөнья булуына да басым ясала. «Метаморфозалар» (1969) шигырендә дә охшаш сурәт тудырыла. Идел, бөре, сабый егет образлары аркылы шагыйрь мәхәббәтне, гомумән, яшәешнең, галәмдәге тормышның нигезе, үзәге итеп күтәрә. «Тормыш» (1969) шигырендә дә мәхәббәт яшәешне дәвам итүче көч югарылыгында бәяләнә.

Мәхәббәт темасы белән янәшәдә мондый стильдәге шигырьләрдә авыл һәм әниләр темасының активлашуы күзәтелә. Әдип асыл ышанычны, рухи кыйбланы татар халкының гореф-гадәтләрендә, өлкән буынның, әнисенең яшәү рәвешендә таба. Мисал өчен, «Юлларым» (1987), «Идел суы» (1987), «Туган ягым» (1976), «Кошлар кайта» (1976-1977), «Хатлар көтәм авылдан» (1991), «Безнең җыр», «Ай батканда, таң атканда» (1990) кебек авыл темасына язылган күпләгән шигырьләрендә гомумкешелек кыйммәтләре, яшәү мәгънәсе турында уйланулар үзәккә куела. Туган як образын лирик-фәлсәфи төсмерләрдә баетып, шагыйрь аны үзенә иң якын, изге урын буларак тәгәлләштерә:

Инешем, ак чишмәм, тауларым,
Талларым, кырларым, кошларым!
Мин сездә күпме җәй җәйләдем,
Мин сездә күпме кыш кышладым! [5, 10 б.]

Авыл, туган як темасы белән янәшә һәрвакыт әни, гомумиләштерелгән Ана образы килә. Әнисенә багышланган шигырьләре белән Р. Вәлиев Аналарның бөеклегенә дан җырлый, аны иң бөек идеал итеп татар укучысына ирештерә. Бу төркем әсәрләр еш кына әниләрдән аерылу яки еракта булу сәбәпле туган сагыш хисе, юксыну кичерешләре белән сугарыла. Мәсәлән, «Сагынам» (1988) шигырендә лирик герой күңелендәге сагыш хисе әнисеннән аерылуга бәйле туа һәм шигырьнең буеннан-буена үстерелә бара:

Су буенда үскән өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый, -
Мин кышларда сине сагынам [5, 160 б.].

Алга таба язгы, җәйге, көзге табигать күренешләре, һәр фасылда әнине сагыну тойгысының үстерелә баруы аркылы «офыкларга карап, һәр көн саен, / сине уйлыйм, сиңа табынам» дип белдергән лирик герой укучыны бер фикергә алып килә: Әнине юксыну хисе Анадан аерылган бала йөрәгендә даими хискә, Әнине сагыну тойгысы яшәү рәвешенә әверелә һәм кеше күңелен мәңгелек сагышка сала! Р. Вәлиевның Аналарга девизга әверелгән «Нигә, әни, нигә картаясың?» (1987-1988) шигырендә дә шушы ук фикерләр дәвам иттерелә.

Мондый әсәрләрдә фольклор стиленең яңарышы шигырьләрнең үлчәмендә, стилендә дә чагылыш таба. «Дулкын» (1967), «Таң җыры» (1986), «Җиңүчегә» (1986), «Кояштай елмай» (1987) һ.б. шигырьләре шушы фикерне дәлилли:

Чем-кара карлыгачлары,
Гөнаһсыз иде яры.
Ник шунда гына калмады?
Ник дулкын китте ары? [5, 156 б.]

Мондый шигырьләрдә татар халык җырларына хас структура күзәтелә: строфаның беренче ике тезмәсендә табигать күренеше тасвирлана, соңгы ике тезмә лирик геройның хис-кичерешләр сәбәбен тергезә. Мондый стильдәге күп кенә шигырьләр татар халык җырларына хас 8/7 үлчәмендә языла.

Халык җырларына хас аһәң, шигырьнең эчке көе, моңы Р. Вәлиевнең бик күп шигырьләрен җыр текстына әйләндерә. Шагыйрьнең аерым шигырьләре хәтта татар халык көйләренә йөз тотып та иҗат ителә. «Дулкын» (1967), «Ай, дуслар» (1988), «Таң җыры» (1986), «Идел суы» (1980), «Бер алманы бишкә бүләек» (1968) һ.б. җырлары шул хакта сөйли:

Бакчалардан былбыл качса,
Көзләр тисә алмагачка,
Кайгы төшсә безнең башка, –
Бер кайгыны бишкә, әй, бүләек [5, 55 б.].

Татар шигъриятендә сирәк очрый торган күренеш: Р. Вәлиевның аерым гражданлык лирикасы үрнәкләре дә җыр булып китә, аларда да күңел лирикасы үрнәкләрендәге кебек эчке аһәң, лирик ритм тудырыла. Мәсәлән, «Ватаным» (1969) шигыре шундыйлардан:

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.
– Сез кайсы халыктан? – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын дип Ватаным [5, 146 б.].

Шушы ук үзенчәлек Р. Яхин, Ә. Бакиров, И. Шәмсетдинов, М. Яруллин, Ф. Әхмәтов, Р. Кәлимуллин, Л. Батыр-Болгари, Р. Әхиярова,

М. Шәмсетдинова, Р. Абдуллин, Ш. Тимербулатов, Л. Хәйретдинова һ.б. күренекле композиторлар көйләр язган «Татарстан» (1968), «Бәхетем башкаласы» (1988), «Саумы, Казан!» (1991) кебек гражданлык лирикасы үрнәкләрендә дә, «Нигә, әни, нигә картаясың?» (1987-1988), 1980 елларда язылган «Зинһар өчен, кермә төшләремә...», «Чаба поезд, чаба» кебек лирик тезмәләрдә дә актуаль булып кала.

Башлангыч чор иҗатында актив гыйсъянчы лирик геройны шәхси кичерешләр өермәсендә тасвирланган, тыныч тормыш матурлыгын җырлаучы лирик герой алмаштырса да, Р. Вәлиев иҗатында җәмгыять гаме, ил һәм халык гаме актуаль булып кала. Туган җир, туган нигез, ата-баба җире, туган туфрак, ватан, нәсел-ыру кебек милли яшәешкә бәйле төшенчәләр аша аның шигырьләрендә әкренләп милли проблемалар калкытып куела башлый. Шулай шагыйрь иҗатында халык өчен, милләт өчен иң мөһим «нигез» кыйммәтләр хакында сөйләшү башлана. Шушы сөйләшү сабантуйлар, йола-гадәтләр, халык тарихында язу, урта гасырлардагы иҗатчылар, тарихтагы аерым сәхифәләр һ.б. турында бик күп шигырьләр иҗат ителүгә китерә. Мәсәлән, беренче карашка көз сурәте тудырылган кебек тәэсир калдырган «...Һәр көз саен таллар телсез калган...» (1970) шигырендә соңгы тезмәләр әсәрдә милли эчтәлекне калкулата. Агач тамыры / нәсел тамыры / милли традицияләр янәшәлеге тудырылып, хәтер, милли тамырлар милләт яшәешенең нигезе, аны алга таба да яшәтүче, көч бирүче үзәк итеп күтәрелә:

Көзге җилләр телем алсалар да,
Тамырымда мәңге калырмын [8, 52 б.].

1970–1990 еллар аралыгында язылган аерым шигырьләрдә тарихи шәхесләр («Сөембикә манарасы», «Агыйделдә боз китә» һ.б.), тарихи хәтер («Кабан күле», «Дисбе», «Илле яшь тутырган абыйлар», «Идел», «Утлы хәтер» һ.б.), тарих («Борынгы Болгарда», «Яңа «Карурман», «Урман» һ.б.), мәдәни мирас («Күздә моң, күңелдә торгынлык» һ.б.) милләтне яшәтүче көч, милли үзаң билгесенә әверелә.

Гражданлык лирикасы үрнәкләрендә гражданин лирик герой алга чыга, ул җәмгыятьтәге яшәеш кануннарына бәя бирергә омтыла, күп вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдерә. Р. Вәлиевнең гражданлык лирикасына мөнәсәбәтле әсәрләрендә кинаяле-асмәгънәле яшерен эчтәлек, эзоп теле алымы активлаша. Нәкъ шул алым совет идеологиясе иләге, цензура аша уза алмаслык күп кенә шигырьләрне укучыга ирештерү мөмкинлеген бирә. Мондый шигырьләрнең күпчелегендә икенчел эчтәлек символлар аша тудырыла, шушы юлда шагыйрь иҗаты традицион символлар белән янәшәдә индивидуаль символлар белән байый. Мисал өчен, «Яз» (1969) шигырендә яз образы өр-яңа мәгънә калыпларында кулланыла. Беренче укылышта ул ил тормышындагы яз, яңарыш тәэсирендә уяну кабул ителә, сынландыру алымы шуңа ишарә ясый:

Утызы да тулмый февраль киткән...
Урамнарга шыплап март тулган.
Агачларның саллы җаясенә
Ук түгел лә... яфрак тартылган [5, 54 б.].

Алдагы строфаларда әлеге яңарышның һәр кеше тормышына, күңеленә кагылып үтүе төгәлләштерелә:

Кайгыларны салыйк гөрләвеккә,
Тургай итеп чөйик шатлыкны!
Яз хәбәрен ишетеп барча кошлар
Безнең якка таба ашыкты [5, 54 б.].

Әнә шулай Р. Вәлиев үз буынына бәя бирә, аларның омтылышлары, зур идеаллар белән янып яшәве укучы күңелендә соклану катыш якты бер моң тудыра. Аларның «ике кулны бөергә куеп сөйләшүе», «күңелләрендәге бозның китүе» ул өметләрнең аклануына ышаныч уята.

1970 еллар башында дөнья күргән «Язгы буран» шигырендә исә язгы буран образы икенчел эчтәлектә җепшеклек сәясәте, XX гасыр уртасындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр, шушы үзгәрешләр дулкынында мәйданга килгән яшь буын булып укыла. Әмма ахырда лирик геройның туңуы ул өметләрнең аклануына шик тудыра, мондый иҗтимагый вазгыять борчылу уята.

Беренче шигырьләреннән булган «Минем эти (Дустым көндәлегеннән)» шигырендә «Минем эти һаман яз аенда! / Минем эти һаман кырык биштә!» дигән юллар укучы игътибарын Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга юнәлтә һәм лирик геройның 45 яшендә сугышта үлгән әтисенә хисләре кебек кабул ителә. Бу юлларның шигырь структурасында кабатланып торуы һәм шигырьне каймалап алуы, тимер кыршау, тарих тәгәрмәче кебек символик образлар кулланылышы башка мәгънәләрне ачу мөмкинлеген дә бирә:

Минем эти
Тапталып үлде...
Тимер кыршау кидергәндә...
Тарих тәгәрмәченә...
Минем эти!.. [5, 19 б.]

«Тарих тәгәрмәченә кидерелгән тимер кыршау» образы төрле дәверләрдә ил тарихы кичергән тарихи фаҗигаләргә ишарәли. Шуңа бәйле шигырь тукымасындагы әрнү хисе шәхси кысалардан чыгып китеп, тарих фаҗигасенә эләккән күп язмышларга бәйле үсеп китә.

Аерым шигырьләр Р. Вәлиевның эзоп теле алымы белән гаять оста эш итә алуын дәлилли. Мисал өчен, беренче карашка туйга бәйле шатлык хисе өстенлек иткән «Авылда туй» (1970) шигырендә урыс капка образы шигырьне бөтенләй башка мәгънәләргә көйли:

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә!..
...Каерып ач урыс капкаларны! –
Керсен бәйрәм татар өенә [5, 70 б.].

Аерым гражданлык лирикасы үрнәкләрендә иҗтимагый фәлсәфә көчәя башлый, әлеге сыйфат шагыйрьгә иҗтимагый эчтәлекне милли эчтәлек белән сугару мөмкинлеген бирә. Мисал өчен, 1970–1980 еллар чигендә иҗат ителгән «Борынгы Болгарда» шигырендә лирик геройның әрнүе тарихи үткән белән бәйләп куела:

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар...
Бабайларның сүзен сөйләр өчен
Тик кылганнар гына калганнар [5, 121 б.].

Шул ук вакытта кылганнар образының татар әдәбиятында калыплашкан традицион эчтәлеге яраклашып яшәргә күнеккән буын мәгънәсен яңарта. Бу очракта лирик геройның әрнүе үз фикере, анык карашы булмаган милләт улларының киләчәгенә тоташа. Яисә шул ук елларда язылган «...Батырлыклар турында язар идем...» шигырендә киная рухи хөрлек булмау турында сөйләүгә юнәлтелә. Беренче карашка «Җәлил яткан төрмәләрне күрсәм» тезмәсе ярдәмендә рухи хөрлек булмау татар шагыйренең язмышына, тоткынлык фаҗигасенә бәйле кабул ителсә, икенче яктан совет тормышына мөнәсәбәтле аңлашыла.

«Үзгәрергә» (1990) шигыре яшәешнең ике чигендә басып торучы кеше фәлсәфәсе буларак та, «җанны талкый һаман заман уе / төште инде сагыш йөзләремә... / яшәп булмый элек яшәгәнчә / кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!» [5, 270 б.] юллары аша җәмгыятьнең үзгәрешләр чорында яшәү кыйбласын эзләгән шәхес халәте кебек тә кабул ителә. Үткән көннәр / яңа көн каршылыгы бу эчтәлекне көчәйтә генә:

Итәгемнән тарта кара төннәр...
Ышаналмыйм кайчак түзәремә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә [5, 270 б.].

Әмма шигырьнең соңгы юлларында өченче эчтәлек ачыла, «без» дип кабатлау аша шагыйрь милли эчтәлеккә ачкыч бирә. Әлеге асмәгънә «Алдан бара әйдәп фидаиләр.../ Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә» һәм «Алдан бара әйдәп фидаиләр.../ Иyртерләр микән үзләренә» [5, 270 б.] дигән юлларга яшерелгән һәм ул авторның татар халкын яңа заманда яңача яшәргә чакыруы булып яңгырый.

Аерым шигырьләрдә эчке эчтәлек символлар ярдәмендә түгел, янәшәлекләр аша ачыла. Мондый шигырьләрдә образ-детальләр аерым әһәмияткә ия һәм алар ачыктан-ачык фикер әйтүгә юнәлтелә. Мәсәлән, «Музейда янгын» (1987-1988) шигырен музей яну һәм милләт тарихы яну ул дигән фикер үтәли кисеп бара. 1990 елларда язылган «Чират» шигырендә исә ит чабучы һәм Палач балтасы янәшәлеге, Ф. Борнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Х. Туфан кебек шәхес культы корбаннары булган татар зыялылары образлары базардагы ит чабу күренешенең асылда үткәндәге ил кичергән фаҗигаләрне тергезүен раслый. Әнә шулай поэтик мөмкинлекләр, образ-символлар кулланылышы шагыйрьгә үз чоры өчен гаять үзенчәлекле фикерләр җиткерү мөмкинлеген бирә.

**Төп нәтиҗәләр**

1. Разил Вәлиев XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар шигърияте үсешенә зур өлеш кертә. Әдәби традицияләрне яңарту һәм трансформацияләү аша ул татар поэзиясендә дәвамчанлыкны һәм яңарышны тәэмин итә.

2. Разил Вәлиев әдәбиятның өч төрендә дә нәтиҗәле эшли: проза өлкәсендә үзенчәлекле әсәрләре белән чыгыш ясый, шигърият мәйданында үз йөзе булган талантлы шагыйрь булып танылa, сәхнә әдәбиятын да үзгә әсәрләр белән баета. Шулай да татар әдәбияты тарихында Шагыйрь булып танылa.

3. Разил Вәлиев шигъриятенең йөзен билгеләүче төп поэтик үзенчәлекләр буларак гыйсъянчылык традицияләрен яңарту, шушы юлда лирик герой концепциясен үзгәртү, фольклор стилен дәвам итү һәм үстерү, гражданлык лирикасын эчке киная һәм иҗтимагый фәлсәфә белән баету билгеләнә.

4. Әдәбиятка сүз сәнгатенең яңа сукмаклар эзләгән чорында килеп, Р. Вәлиев аның үсеше өчен яңа мөмкинлекләр таба, үз иҗат үрнәкләре белән татар шигъриятендә лирик герой концепциясен үзгәртү, кыю фикерләр җиткерү мөмкинлекләрен дәлилли.

### Йомгак

Шул рәвешле, Разил Вәлиев күпкырлы иҗаты белән татар шигъриятенә үзгә сулыш өрә. Иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Кеше» (1968) шигырендә ул үзенең яшәү һәм иҗат итү кредосын билгеләп, болай дип яза:

Күпме тырышсаң да булмый мине
Хәят диңгезендә батырып! [5, 35 б.].

Үз кичерешләре аша халык язмышын җиткерә алган, халкының бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылган, кешелекнең рухын яңарту идеалы белән янган шигърияте Р.Вәлиевның үз мәсләгенә тугры калуын дәлилли. XX гасыр уртасында милли традицияләрне тергезеп, аларны яңа алымнар белән баетып, сүз-сурәт тудыруның яңа алымнарын тергезеп, ул татар шигъриятенә кабатланмас, бай һәм күпкырлы иҗат калдырды.

**Әдәбият**


1. *Вәлиев Р.* Зәңгәр кабырчыклар: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 93 б.
2. *Вәлиев Р.* Яшен тамыры: шигырьләр һәм җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 127 б.
3. *Вәлиев Р.* Ядкарь: шигырьләр, җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 144 б.
4. *Вәлиев Р.* Бер алманы бишкә бүләек: җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 144 б.
5. *Вәлиев Р.* Кышкы учак. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 382 б.
6. *Вәлиев Р.* Сүзләрдән дисбе: шигырьләр, җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 224 б.
7. *Вәлиев Р.* Сайланма әсәрләр: шигырьләр, җырлар. 4 китапта. Кит.1: шигырьләр, җырлар. Казан: Милли китап, 1999. 568 б.
8. *Вәлиев Р.* Әсәрләр: шигырьләр, җырлар: 4 томда. Т.1: Шигырьләр, җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 527 б.
9. *Вәлиев Р.* Күз балкышы: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 279 б.
10. *Вәлиев Р.* Мәхәббәт һәм нәфрәт: шигырьләр, повестьлар, истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 543 б.
11. *Ошанин Л.* Разил Вәлиев // Казан утлары. 1979. №10. Б.80–82.
12. *Галиев М.* Язмышка рәхмәт // Галиев М. Рух: фәлсәфи язмалар, әдәби портретлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 332-355.
13. *Госманов М.* Алтын бусаганы атлаганда // Госманов М. Гасырдан – гасырга. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б.334–339.
14. *Хисамов Н.* Кеше атлы бер кыйтга мин... // Мәдәни җомга. 2010. 24 дек. Б. 14-15.
15. *Хисамов Н.* Иҗатчының шигъри дөньясы // Н.Хисамов. Татар шагыйрьләре: монографик мәкаләләр, иҗат портретлары һәм этюдлар. Казан: Татар кит. нәшр., 2012. Б. 239-247.
16. *Заһидуллина Д.* Разил Вәлиев // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 7: 1985–2000 еллар. Казан: «Фолиант» нәшр., 2019. Б. 289–309.
17. *Зәйдулла Р.* Дулкын биеклеге // Вәлиев Р. Күз балкышы: шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 2-7.
18. *Миңнуллин Т.* Талантлы буынның бер вәкиле // Мәдәни җомга. 2016. 16 дек. Б. 8–9.
19. *Гаташ Р.* Дөнья гамен җанга уйдырып... // Мәдәни җомга. 2012. 6 апрель. Хәсәнова А. Шагыйрь дисбесе: [иҗат кичәсе тур.] // Ватаным Татарстан. 2012. 11 апрель. Б. 2.
20. *Ятимова Ф.* Особенности языка и стиля поэзии Разиля Валиева: автореферат дисс... канд. филол. наук. Казань, 2008. 22 с.
21. Терминология современного зарубежного литературоведения. (Страны Западной Европы и США) / отв. ред.: Ильин И.П., Цурганова Е.А. М.: ИНИОН, 1992. 218 с.
22. *Борухов Б.* Введение в мотивирующую поэтику // Филологическая герменевтика и общая стилистика. Тверь: Изд-во Тверского ун-та, 1992. С. 5 – 28.
23. *Йосыпова Н.* XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык. Казан: «Школа» редакция нәшрият үзәге, 2021. 296 б.


---

# «СОБИРАЮ ЧЕТКИ ИЗ СЛОВ...»: СВОЕОБРАЗИЕ ПОЭЗИИ РАЗИЛЯ ВАЛЕЕВА


**Нурфия Марсовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.



В статье, посвященной жизненному и творческому пути Разиля Валеева, выявлено место поэта в татарской поэзии второй половины XX – начала XXI века. Произведения писателя проанализированы сквозь призму проблемы традиции и новаторства. Р. Валеев плодотворно работал в трех видах словесного искусства. Значительных результатов ему удалось достичь на по-

этическом поприще. Многие стихотворения Р. Валеева стали для татарской поэзии «программными». В ходе анализа литературного процесса второй половины XX – начала XXI века раскрыты особенности лирического героя его поэзии, выявлены открытия поэта в системе мотивов. Доказано, что Р. Валеев в процессе творческих поисков возрождает традиции бунтарской поэзии в духе Хади Такташа, создает уникальный символический ряд образов, успешно применяет эзопов язык, прибегает к фольклорным образам для достижения лиризма.

**Ключевые слова:** Разиль Валеев, лирический герой, поэзия, образ, жанр, мотив, литературный прием, эзопов язык, фольклорный стиль, гисианизм